РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТИМЕРШИКСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422057, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Тимершик, ул. Пионерская, 19 а
тел. (84362) 2-23-23

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
ТИМЕРШЫК АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
422057, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Тимершык авылы, Пионер урамы,
19 а йорт
тел. (84362) 2-23-23

e-mail: Timer.Sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.04.2019 №24п

Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитетының
2017 елның 15 мартында 9п номер белән расланган
"Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитеты
тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү
өчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәте күрсәтү
Административ регламентын раслау турында" карарына
үзгәрешләр кертү турында

ТР Саба районы прокуратурасының 2019 елның 3 нче апрелендәге 02-08-02-61-2019 нчы номерлы протесты нигезендә, Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Тимершы кавыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 15 мартында 9п номер белән расланган "Тимершык авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан алдан төзелгән территорияләрне үстерү өчен җир кишәрлеге бирү" муниципаль хезмәте күрсәтү Административ регламентын раслау турында" карарының 5.1 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 10 пунктча белән тулыландырырга:

- Гариза бирүчедән дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәткәндә, дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документлар яки мәгълүматларның юклыгы яки төгәлсезлеге беренче тапкыр документларны кабул иткәндә күрсәтелмәгәндә, яисә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 7 статьясы 1 бүлеге 4 пункты белән каралган очраклардан тыш, документлар яки мәгълүматлар таләп итү. Күрсәтелгән очракта, гариза бирүче тарафыннан судка кадәр (судсыз) күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең гамәлләрен(гамәл кылмавын) шикаять итү, мөмкин шул очракта, әгәр карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) шикаять ителүче күпфункцияле үзәккә "Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" Федераль законның 16 статьясы 1.3 бүлеге белән билгеләнгән тәртиптә

дәүләт яки муниципаль хезмәт күрсәтү функциясе тулы күләмдә йөкләнгән булса.

- 5.8 пунктны түбәндәгечә бәян итәргә:

Шикаятьне карау яки караганнан соң барлыкка килгән нәтиҗәләр буенча административ хокук бозу яки җинаять очрагы расланган очракта, шикаятьләрне карауга вәкаләтле хезмәткәр яки вазыйфаи зат “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” Федераль законның 11.2 статьясы 1 бүлегенә туры китереп, булган материалларны прокуратура органнарына җибәрә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Тимершык  авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/timershik адресы буенча урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Х. Хаҗиев